ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

_______________          с. Верхний Услон          _______________

## Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Югары Ослан районы халкының яшәүнең уңай шартларына хокукларын, җир участоклары һәм ныгытылган төзелеш объектлары хокук ияләренең хокук һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү турында Нигезләмә нигезендә, Д. С. Кузнецов мөрәҗәгатен карап.

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Югары Ослан авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре шәхси торак төзелеш зонасында (Ж1) Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авыл җирлеге, Югары Ослан авылы, Каюм Насыйри урамы, 22 нче йорт адресы буенча 1143 кв. м мәйданлы, кадастр номеры 16:15:050501:609 булган җир кишәрлегеннән «кунакханә хезмәте»нә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләргә.

2. Оештыручы буларак, 1 нче пунктта күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгать фикер алышуларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген билгеләргә (алга таба - җәмәгать фикер алышуларны оештыручы).

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы - коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ә. Әхмәтшин;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы А.Д. Сагдеева;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының оештырыш-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге начальнигы Н.В. Пичугина;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Т.М. Дәүләтшин.

4. Җәмгыять фикер алышуларын оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җәмгыять таләпнәрен оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Җәмгыять фикер алышуларын үткәрү чорын билгеләргә - 2026 елның 25 мартыннан 2026 елның 13 апрелена кадәр.

6. Җәмгыять фикер алышуларын оештыручыга РФның Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 ст. нигезендә җәмгыять фикер алышулары башлануы турында хәбәр әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин